КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 31 октябрь г.Казань № 991

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын тормышка ашыру чаралары турында» 2019 ел, 30 июль, 634 нче карары белән расланган 2019 елда «Сиделка» хезмәте күрсәтү буенча пилот проектын тормышка ашыру кысаларында «Сиделка» хезмәте күрсәтү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын тормышка ашыру чаралары турында» 2019 ел, 30 июль, 634 нче карары белән расланган 2019 елда «Сиделка» хезмәте күрсәтү буенча пилот проектын тормышка ашыру кысаларында «Сиделка» хезмәте күрсәтү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

III бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.3 пункт өстәргә:

«3.3. «Сиделка» хезмәте түләүсез күрсәтелә.»;

IV бүлек үз көчен югалткан дип санарга;

V бүлекнең 5.3 пунктындагы җиденче абзацны төшереп калдырырга;

VI бүлектә:

6.1 пунктка ««Сиделка» хезмәтен сатып алуга (алга таба – контракт)» сүзләрен өстәргә;

6.3 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сиделка» хезмәте күрсәтү өчен түләү тәртибе, вакытлары һәм шартлары;»;

6.8 пунктның 7 пунктчасы үз көчен югалткан дип санарга;

VIII бүлекнең 8.3, 8.4 пунктлары үз көчен югалткан дип санарга;

IX бүлекнең 9.3 нче пунктындагы бишенче абзацка «, түбәндәге формула буенча:

$$S = \frac{V}{W},$$

монда:

V – хезмәт күрсәтүче комплекслы үзәк белән төзелгән контракт бәясе;

W – контрактта каралган «Сиделка» хезмәте күрсәтү сәгатьләре саны;» сүзләрен өстәргә.

2. Бу карарның гамәле 2019 елның 30 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин